КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 август г.Казань № 1019

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 939 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәнең 3 нче кушымтасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 939 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1276 нчы; 2022 ел, 22 июль, 713 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәнең 3 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 25 август, 1019 нчы карары редакциясендә)

Лицензия контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган лицензия таләпләрен бозу рискы индикаторлары

1. Өч ай рәттән Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йорт бүлмәләре милекчеләренең шундый ук көн тәртибе мәсьәләләре буенча карарлардан гыйбарәт ике һәм аннан күбрәк гомуми җыелыш беркетмәләре керү.

2. Өч ай дәвамында гражданнан яки күпфатирлы йорт бүлмәләре милекчеләре булган оешмадан, күпфатирлы йорт бүлмәсеннән файдаланучы гражданнан алынган белешмә (мәгълүмат), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат һәм торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында контрольдә тотылучы зат тарафыннан урнаштырылган мәгълүмат туры килми торган (дөрес булмаган) биштән артык факт ачыклану.